СОВЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2025 елның 28 марты № 45/5

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының муниципаль контроль турында аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 28 декабрендәге 540-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Чүпрәле районы прокурорының протестларын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2021 елның 15 декабрендәге 14/8 номерлы «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында нигезләмәне раслау хакында» карарына (03.02.2022 № 16/3, 28.03.2023 № 27/6, 09.11.2023 № 32/9, 29.05.2024, № 38/3 редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**25 пунктның беренче абзацында** «, контрольдә тотылучы затның мәҗбүри таләпләрне бозуга китерергә яисә китерергә мөмкин булган гамәлләре (гамәл кылмавы) нәтиҗәсендә барлыкка килгән зыяннарны бетерү сроклары» сүзләрен өстәргә;

**43 пунктта** «Контроль чарасы» сүзләреннән соң «, контрольдә тотыла торган зат белән үзара хезмәттәшлек итүне күздә тота торган» сүзләрен өстәргә, «мәҗбүри таләпләрне үтәүне һәм урынга барып тикшерүне күзәтүне, шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга;

**56 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«56. Документлар буенча тикшерүне үткәрү вакыты ун эш көненнән артмаска тиеш. Контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан тикшерелүче затка документлар буенча тикшерү барышында карау өчен кирәкле документларны таләптә күрсәтелгән документларны контроль (күзәтчелек) органына тапшырган вакытка кадәр, шулай ук тикшерелүче затка контроль (күзәтчелек) органыннан тикшерелүче зат тарафыннан тапшырылган хаталарны һәм (яисә) каршылыкларны ачыклау турында мәгълүмат җибәрелгән вакыттан алып тикшерелүче зат тарафыннан тапшырылган документларда йә бу

документлардагы белешмәләрнең контроль (күзәтчелек) органында булган документлардагы һәм (яисә) дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда алынган белешмәләргә туры килмәве турында таләпләр, һәм кирәкле язма аңлатмаларны тапшыру таләпләре бирелгән вакыттан алып, күрсәтелгән язма аңлатмаларны контроль (күзәтчелек) органына тапшырганчыга кадәр чорга документлар буенча тикшерү үткәрү срогын исәпләү туктатылып тора.»;

**57 пунктны түбәндәге** редакциядә бәян итәргә:

57. Планнан тыш документар тикшерү, 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4, 6, 8 пунктлары буенча үткәрелгән очрагыннан тыш, прокуратура органнары белән килештереп кенә үткәрелергә мөмкин.»;

**60 пунктта** «3 - 6» саннарын «3, 4, 6, 8» саннарына, «һәм 66 статьяның 12 өлешендә» сүзләрен «66 статьясындагы 12 өлешендә һәм 75 статьясындагы 7 өлешендә» сүзләренә алмаштырырга;

**62 пунктның дүртенче абзацын** үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2021 елның 15 декабрендәге 14/9 номерлы «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» карарына (03.02.2022 № 16/3, 28.03.2023 № 27/6, 09.11.2023 № 32/9, 29.05.2024 № 38/3 редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**3.4 бүлекне** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Профилактик визит

1. Профилактик визит контрольдә тотыла торган зат эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча инспектор тарафыннан кисәтү әңгәмәсе рәвешендә йә «Инспектор» видео-конференция-элемтә яисә мобиль кушымтасыннан файдалану юлы белән уздырыла.

2. Тикшерү визиты барышында контрольдә тотылучы зат аның эшчәнлегенә карата йә аңа караган контроль объектларына карата, аларның хәвеф-хәтәр критерийларына туры килүе, хәвеф-хәтәр категориясен киметүнең тәкъдим ителә торган ысуллары, куркынычның тиешле категориясенә кертүдән чыгып, тикшерү объектына карата үткәрелә торган чараларның төрләре, эчтәлеге һәм интенсивлыгы буенча куела торган мәҗбүри таләпләр турында хәбәр ителә, ә инспектор контроль объекты белән таныша, контроль объектларын хәвеф-хәтәр категориясенә кертү өчен кирәкле белешмәләр җыя, һәм контрольдә тотылучы затның мәҗбүри таләпләрне үтәү дәрәҗәсен бәяли.

3. Профилактик визит контроль (күзәтчелек) органы инициативасы буенча (мәҗбүри профилактик визит) яисә контрольдә тотыла торган зат инициативасы буенча уздырыла.

4. Тикшерү объектына профилактика визитын уздыру йомгаклары буенча 248-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясындагы 6 һәм 7 өлешләре нигезендә мәҗбүри таләпләрне үтәү дәрәҗәсен ачык бәяләү бирелергә мөмкин.»;

**4.1.5 пунктының унҗиденче абзацында** «мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтүне, урынга барып тикшерүне» сүзләрен «үзара хезмәттәшлексез контроль (күзәтчелек) чараларын» сүзләренә алмаштырырга;

**4.5.3 пункты** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5.3. Документлар буенча тикшерүне үткәрү вакыты ун эш көненнән артмаска тиеш. Контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан тикшерелүче затка документлар буенча тикшерү барышында карау өчен кирәкле документларны таләптә күрсәтелгән документларны контроль (күзәтчелек) органына тапшырган вакытка кадәр, шулай ук тикшерелүче затка контроль (күзәтчелек) органыннан тикшерелүче зат тарафыннан тапшырылган хаталарны һәм (яисә) каршылыкларны ачыклау турында мәгълүмат җибәрелгән вакыттан алып тикшерелүче зат тарафыннан тапшырылган документларда йә бу документлардагы белешмәләрнең контроль (күзәтчелек) органында булган документлардагы һәм (яисә) дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда алынган белешмәләргә туры килмәве турында таләпләр, һәм кирәкле язма аңлатмаларны тапшыру таләпләре бирелгән вакыттан алып, күрсәтелгән язма аңлатмаларны контроль (күзәтчелек) органына тапшырганчыга кадәр чорга документлар буенча тикшерү үткәрү срогын исәпләү туктатылып тора.»;

**4.5.10 пункт** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5.10. Планнан тыш документар тикшерү прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин, моңа 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4, 6, 8 пунктлары нигезендә тикшерү уздырылган очрак керми.»;

**4.9.3 пунктының икенче абзацы** үз көчен югалткан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2021 елның 15 декабрендәге 14/10 номерлы карарына (03.02.2022 № 16/3, 28.03.2023, № 27/6, 09.11 № 32/9, 29.05.2024 № 38/3) «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**3.4 бүлекне** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Профилактик визит

1. Профилактик визит контрольдә тотыла торган зат эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча инспектор тарафыннан кисәтү әңгәмәсе рәвешендә йә «Инспектор» видео-конференция-элемтә яисә мобиль кушымтасыннан файдалану юлы белән уздырыла.

2. Тикшерү визиты барышында контрольдә тотылучы зат аның эшчәнлегенә карата йә аңа караган контроль объектларына карата, аларның хәвеф-хәтәр критерийларына туры килүе, хәвеф-хәтәр категориясен киметүнең тәкъдим ителә торган ысуллары, куркынычның тиешле категориясенә кертүдән чыгып, тикшерү объектына карата үткәрелә торган чараларның төрләре, эчтәлеге һәм

интенсивлыгы буенча куела торган мәҗбүри таләпләр турында хәбәр итеңә, ә инспектор контроль объекты белән таныша, контроль объектларын хәвеф-хәтәр категориясенә кертү өчен кирәкле белешмәләр җыя, һәм контрольдә тотылучы затның мәҗбүри таләпләрне үтәү дәрәҗәсен бәяли.

3. Профилактик визит контроль (күзәтчелек) органы инициативасы буенча (мәҗбүри профилактик визит) яисә контрольдә тотыла торган зат инициативасы буенча уздырыла.

4. Тикшерү объектына профилактика визитын уздыру йомгаклары буенча 248-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясындагы 6 һәм 7 өлешләре нигезендә мәҗбүри таләпләрне үтәү дәрәҗәсен ачык бәяләү бирелергә мөмкин.”;

**4.1.5 пунктының унҗиденче абзацында** «мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтүне, урынга барып тикшерүне» сүзләрен «үзара хезмәттәшлексез контроль (күзәтчелек) чараларын» сүзләренә алмаштырырга;

**4.5.3 пункты** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5.3. Документлар буенча тикшерүне үткәрү вакыты ун эш көненнән артмаска тиеш. Контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан тикшерелүче затка документлар буенча тикшерү барышында карау өчен кирәкле документларны таләптә күрсәтелгән документларны контроль (күзәтчелек) органына тапшырган вакытка кадәр, шулай ук тикшерелүче затка контроль (күзәтчелек) органыннан тикшерелүче зат тарафыннан тапшырылган хаталарны һәм (яисә) каршылыкларны ачыклау турында мәгълүмат җибәрелгән вакыттан алып тикшерелүче зат тарафыннан тапшырылган документларда йә бу документлардагы белешмәләрнең контроль (күзәтчелек) органында булган документлардагы һәм (яисә) дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда алынган белешмәләргә туры килмәве турында таләпләр, һәм кирәкле язма аңлатмаларны тапшыру таләпләре бирелгән вакыттан алып, күрсәтелгән язма аңлатмаларны контроль (күзәтчелек) органына тапшырганчыга кадәр чорга документлар буенча тикшерү үткәрү срогын исәпләү туктатылып тора.»;

**4.5.10 пункт** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5.10. Планнан тыш документар тикшерү прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин, моңа 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4, 6, 8 пунктлары нигезендә тикшерү уздырылган очрак керми.»;

**4.9.3 пунктының икенче абзацы** үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставы нигезендә рәсми басылып чыгарга тиеш.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе М.Р. Гафаров